**Казан шәһәре Башкарма комитетының**
**2025 елның 14 гыйнварындагы 29 номерлы карары**

**Казан шәһәре Башкарма комитетының**
**2023 елның 11 октябрендәге 3059 номерлы**
**«Махсус хәрби операциядә катнашу максатыннан**
**Россия Федерациясе Кораллы Көчләрендә хәрби хезмәт узу**
**турында контракт төзегән Россия Федерациясе гражданнарына**
**бер тапкыр акчалата түләү бирү тәртибен раслау хакында»гы**
**карарына үзгәрешләр кертү турында**

Россия Федерациясе Кораллы Көчләрендә хәрби хезмәт узу турында контракт төзегән Россия Федерациясе гражданнарына бер тапкыр акчалата түләү бирү вакытын төгәлләштерелүгә бәйле рәвештә, шулай ук кадрлар үзгәрүенә бәйле рәвештә **карар бирәм:**

1. Казан шәһәре Башкарма комитетының 2023 елның 11 октябрендәге 3059 номерлы «Махсус хәрби операциядә катнашу максатыннан Россия Федерациясе Кораллы Көчләрендә хәрби хезмәт узу турында контракт төзегән Россия Федерациясе гражданнарына бер тапкыр акчалата түләү бирү тәртибен раслау хакында»гы карарына (аңа Казан шәһәре Башкарма комитетының 2023 елның 27 октябрендәге 3247 номерлы, 2023 елның 15 ноябрендәге 3493 номерлы, 2023 елның 22 ноябрендәге 3611 номерлы, 2023 елның 1 декабрендәге 3783 номерлы, 2023 елның 19 декабрендәге 4158 номерлы, 2024 елның 26 гыйнварындагы 238 номерлы, 2024 елның 29 мартындагы 1222 номерлы, 2024 елның 1 июлендәге 2750 номерлы, 2024 елның 11 июлендәге 2969 номерлы, 2024 елның 2 ноябрендәге 4625 номерлы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. карарның 1 номерлы кушымтасындагы 2.2 пунктны түбәндәге редакциядә бирергә:

«2.1. Бер тапкыр бирелә торган түләү Казан шәһәре районнарындагы хәрби комиссариатларның бирсенә яисә «Батыр» контракт буенча хәрби хезмәткә рәсмиләштерү үзәгенә шәхсән мөрәҗәгать иткән һәм Казан шәһәренең контракт буенча хәрби хезмәткә (1 нче разрядлы) сайлап алу пунктында махсус хәрби операциядә катнашу максатыннан Россия Федерациясе Кораллы Көчләрендә хәрби хезмәт узу турында бер елга яки аннан күбрәккә контракт (алга таба – Контракт) төзегән Россия Федерациясе гражданнарына бер тапкыр бирелә. Бер тапкыр бирелә торган түләү җинаятьләр кылган һәм Россия Федерациясе Җинаять-процессуаль кодексының 208 статьясындагы беренче өлешенең 3.1 пункты нигезендә алдан тикшерү туктатылган затларга, шулай ук иректән мәхрүм итү рәвешендә җәза үтәүче затларга бирелми»;

1.2. карарның 1 номерлы кушымтасындагы 2.2 пунктны түбәндәге редакциядә бирергә:

«2.2. Бер тапкыр бирелә торган түләү 2023 елның 11 октябреннән 2024 елның 3 ноябренә кадәрге һәм 2025 елның 3 гыйнварыннан 2025 елның 1 июленә кадәрге чорларда Контракт төзегән гражданнарга бирелә»;

1.3. карарның 3 номерлы кушымтасында:

1.3.1. Т.М.Кадыйровны комиссия составыннан чыгарырга;

1.3.2. комиссия составына комиссия сәркатибе буларак Гайфетдинова Гөлназ Харис кызын, Казан шәһәре Башкарма комитеты Аппараты социаль сәясәт идарәсенең социаль проектлар бүлеге башлыгын кертергә.

2. Әлеге карарны «Муниципаль хокукый актлар һәм башка рәсми мәгълүмат» челтәр басмасында (www.docskzn.ru) бастырырга, Казан шәһәре җирле үзидарә органнарының рәсми порталында (www.kzn.ru) һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Казан шәһәре Башкарма комитеты Аппараты җитәкчесе Б.Р.Алиевкә йөкләргә.

**Җитәкче** **Р.Г.Гафаров**